**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Иске Суыксу авыл җирлеге составына керүче Иске Суыксу торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре карары**

**25 ноябрь 2020 ел** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «Иске Суыксу авыл җирлегенең Иске Суыксу авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2021 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – Иске Суыксу авылында юлларны төзекләндерүгә Сез ризамы?» дигән сорау буенча 2020 елның 25 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыененың нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә, халык җыенында катнашучы 901 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 551 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашкан 551 кеше «әйе» позициясе өчен тавыш бирде;

«каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Согласно протоколу о результатах схода граждан:

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Буа муниципаль районы Иске Суыксу авыл җирлеге составына керүче Иске Суыксу авылында халык җыенын узган дип, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.
2. «Иске Суыксу авыл җирлегенең Иске Суыксу авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2021 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – Иске Суыксу авылында юлларны төзекләндерүгә Сез ризамы?» дигән сорау буенча карар кабул ителгән дип танырга.
3. Буа муниципаль районының рәсми сайтында һәм Иске Суыксу авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халык җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Иске Суыксу авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: __________ И.Г. Әхмәтшин

Иске Суыксу авыл җирлеге
башлыгы __________ И.Г. Әхмәтшин